ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОРОМАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ РОМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422970, Республика Татарстан,
Чистопольский район, с.Старое Ромашкино,
ул.Центральная, 30 Б

422970, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Иске Роман авылы,
Центральная урамы, 30 Б

тел. 8(84342) 3 -10-13 E-mail: Strom.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар
№ 7 2021 елның 12 апреле

Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җибәрелгән техник хатага бәйле рәвештә Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 мартындагы 4 номерлы карарына 2 пунктның икенче абзацын бәян итеп, түбәндәге редакциядә түбәндәге үзгәреш кертергә:

«2018 елның 18 июнендәге 9 номерлы «Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»;».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г.Дәүләтшина